Кукмара районы Кәркәвеч урта мәктәбе

# "Гомерем бишеге син, Кукмарам!"

## Татар теле һәм әдбияты дәресләрендә, дәрестән тыш эшләрдә милли төбәк компоненты.

Кәркәвеч урта мәктәбенең
югары категорияле укытучысы
Хакова Роза Габдрахман кызының
**авторлык программасы**

# Аңлатма язуы

Халыкның тарихын, мәдәниятен, мәгарифен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү укучы яши торган авыл, район, республика, аның кешеләре турында мәгълүмат туплаудан башлана. Шул мәгълүматларны укыту программасына кертү фәннең милли - төбәк компонентын тәшкил итә. Милли - төбәк компонентын өйрәнүнең берничә юнәлеше бар:

- укучыларны төбәкнең тарихы, мәгарифе, мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыру;
- танылган кешеләрнең эшчәнлеген өйрәнү, очрашулар оештыру;
- үз төбәгендә яшәүче башка халыкларның тарихы, мәдәнияте, гореф - гадәтләренә ихтирам хисе тәрбияләү;
- укучыларның танып - белү активлыгын, милли үзаңын үстерү;
- туган якның тел үзенчәлекләрен өйрәнү.

Укыту - тәрбия эшендә милли төбәк компонентын кертү гуманистик кыйммәтләрне һәм шул ук вакытта төбәкнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Милли компонент укучыларда белем алуга омтылыш уятуга стимул булып тора.

Милли - төбәк компонентын дәресләрдә генә түгел, сыйныфтан тыш чараларда өйрәнү бик әһәмиятле.

Милли- төбәк компоненты - бик киң төшенчә. Ул үз районыңнан чыккан әдипләр, җырчылар тормышын өйрәнүгә генә кайтып калмый. Аның нигезе үзең укыган мәктәп, туган авыл, аның чишмә- болыннарыннан, бишек җырларыннан башлана.

Бу программа 26 сәгатькә исәпләнеп, гомуми педагогик таләпләргә:

- төбәк турындагы мәгълүматларның дәрес, тема эчтәлеге белән бәйләнештә булырлык;
- һәр өстәмә мәгълүмат аңлаешлы, үзләштерелерлек, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килерлек итеп төзелде.

Милли - төбәк компонентын куллану укучыларның иҗади эшчәнлеге, эзләнүләре белән берлектә алып барыла. Теге яки бу теманы өйрәнү бер дәрестә генә тәмамланмый, ул берничә этаптан тора:

- укытучы дәрестә теманы ача, укучы күңеленә эзләнү орлыгы сала;
- укучылар материал туплый;
- материал укытучы җитәкчелегендә анализлана;
- укучылар тарафыннан альбомнар төзү, рефератлар язу, презентацияләр әзерләү эше башкарыла;
- класстан тыш чараларда, фәнни конференцияләрдә эшләнгән эшләргә отчет ясала.

Милли - төбәк компонентын туплау, өйрәнү, гамәлгә кую белем алуга кызыксынуны арттыра, яшь буында әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итә, укучы шәхесенең үсешенә зур йогынты ясый, иҗади активлыкка этәргеч бирә.

| Тема | Максат | Нинди темага бәйле үткәрелә | Файдалану өчен материал |
|---|---|---|---|
| Кереш. Кукмарам– гомерем бишеге. | Районның 75 елда ирешелгән уңышлары | | "Хезмәт данында" басылган мәкаләләр. |
| Район, туган авылым исемнәре ни сөйли? | Кукмара, Салтык – Ерыклы, Ташлы –Елга, Бурсык – Елга ойконим-нарын өйрәнү. | 6 кл. Ялгызлык исемнәр, 11кл. Топонимнар. | Г. Ф. Саттаров "Мәктәптә туган як ономастикасы" К. 1984. |
| Туган як топонимнары. | Авылларның гидронимнарын өйрәнү. | 6 кл. Ялгызлык исемнәр, 11кл. Топонимнар. | Ф. Саттаров "Мәктәптә туган як ономастикасы" К. 1984. |
| Туган як топонимнары. | Авылларга бәйле оронимнарны өйрәнү | 6 кл. Ялгызлык исемнәр, 11кл. Топонимнар. | Ф. Саттаров "Мәктәптә туган як ономастикасы" К. 1984. |
| Мәктәпнең тарихи музеена сәяхәт. | Музей белән танышу, музей өчен материал туплауга әзерлек. | 7кл. С. Хәким иҗаты | |
| Безнең сөйләмебез. | Диалект, диалекталь сүзләр белән таныштыру | 9 кл. Лексика. | "Татар теленең диалектологик сүзлеге" К. 1969. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. "Әбиемнең әйтер сүзе бар". | Җирле фольклор үрнәкләре белән танышу. | 6 кл. Фигыль | Фольклор үрнәкләре. |
| Авыл, район мәгарифе тарихы. Мәчкәрә мәдрәсәсе. | Мәктәп – мәдрәсәләрнең милли үсешкә керткән өлешен, мәктәпләрнең тарихын өйрәнү. | 9 кл. Р. Фәх-ретдинов, К. Насыйри иҗатлары | Архив, музей материаллары. |
| Кемнән үрнәк алырга? | Укытучылар династиясен өйрәнү, презентация эшләү. | 6кл. Ч.Айтматов "Беренче мөгаллим" | "Хезмәт даны" 94.№83, 91. № 28, 29 87. № 82 2000. 79, 80 |
| Т. Яхин – мәгърифәтче. | Тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында мәгълүмат. | 9 кл. Р. Фәх-ретдинов, К. Насыйри иҗатлары | М. Мәһдиев "Әдәбия һәм чынбарлык" К. 1987 |
| Кукмарам – күпмилләтле төбәк. | Милләтләр арасында дуслык. | 9 кл. Икетеллелек. | "Кукмара географиясе" |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. "Әйләнеп карыйк артка,әби – бабайлар яшәгән чакка". | Авылларда милли гореф – гадәт, йолалар белән танышу. | 8 кл. Бәширов"Туган ягым –яшел бишек". | Видеотасма -"Каз өмәсе", тарихи истәлекләр. |
| "Исемең матур, кемнәр куйган?" | Исемнәрнең мәгънәсенә төшенү. Исем куюга җитди карарга өйрәтү. | 11кл. Ономастика. | Г.Саттаров "Татар исемнәре ни сөйли?" |
| Район матбугаты тарихы. | "Хезмәт даны" газетасы, аның тарихы белән танышу. | 10 кл. 20 йөз башы татар әдәбияты. Матбугат һәм культура үсеше. | Архив материаллары. "Хезмәт даны" газетасы төпләмәсе. |
| Редакциягә экскурсия. | Журналистлык эшчәнлеге белән танышу, газета чыгару серләренә төшенү. | 9 кл. Стильләр. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сәнгатькә гашыйк шәхесләр. Г.Шәрәфиев, Р. Муллин, Н. Мөхәммәтҗанов. | Тормыш һәм иҗатларына күзәтү. | 11 кл. "Драматургия" темасыннан соң. | Видеотасмалар, "Юлдаш" газетасы материаллары. |
| Җирнең чын хуҗалары. | Төбәкнең хезмәт алдынгыларын барлау, өйрәнү. | 11 кл. "Проза" темасыннан соң. | "Хезмәт даны" газеталары материаллары. |
| Р. Сибат – күренекле язучы. "Көлдән күтәрелгән гөлләр" китабын тәгъдир итү. | Язучы иҗаты белән танышу, китабына күзәтү ясау, сүз сәнгатенең тәэсир итү көче. | 11 кл. Г.Бәширов "Намус". | Р. Сибат китаплары. |
| З. Мәхмүди- фантастик язучы. | Фантастик әсәрлә үрнәге белән танышу. | 7 кл. К. Насыйри "Әбугаласина". | З. Мәхмүди китаплары. |
| Р. Бәшәр – балалар язучысы. | Язучының тормышы, иҗатын өйрәнү. | 7 кл. Р, Миңнуллин иҗатыннан соң. | "Якташ язучылар" Кукмара, 2003. |
| Якташыбыз- горурлыгыбыз М. Насыйбуллин. | Күпкырлы талантын, яшь буын өчен тәрбияви көчен билгеләү. | 9 кл. З. Бигиев "Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә". | "Телсез шаһитләр, "Алтын алка" |
| Үлгәннәрнең калган гомерләре ал таңнарга кушылып кабына. | Үлгәннәрне ихтирам , исәннәргә игътибар кирәклеген аңлату. | 11 кл."Проза" темасын өйрәнгәч. | "Хәтер"китабы. |
| М.Усманов – сәнгатькә гашыйк шәхес. | Тормышы,иҗаты белән танышу. | 11 кл. "Хәзинә" романы | "Якташ язучылар" Кукмара, 2003. |
| Ф.Әхмәт музеена экскурсия. | Экспонатлар аша шәхесне аңларга өйрәтү. | Уку елы тәмамланганда | Салтык-Ерыклы авылындагы Ф.Әхмәт музее, экспонатлар. |
| Бәйләнешле сөйләм стерү. Кукмарага багышлап язылган җырларга күзәтү. | Милли горурлык хисе тәрбияләү. | 11кл. "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында"гы Закон. | Җыр китаплары, караоке |
| "Туган ягым буйлап"- презентация. | Милли төбәк компонентының тәрбияви көче. | Мәктәпнең фәнни түгәрәк отчетында. | Презентация үрнәкләре |

**Об авторской программе "Национально-региональный компонент на уроках татарского языка и лнтературы, во внеклассной деятельности».**

**Автор программы Хакова Роза Габдрахмановна,** учительница высшей категория Каркаусской среднеи общеобразовательной школы Кукморского муниципального района Республики Татарстан.

Авторская программа начинается с «Пояснительной записки». Автор поясняет актуальность проблемы, цели, задачи по внедрению национально-регионального компонента.

Роза Габдрахмановна умело выбирает самое нужное, так как региональный компонент - обширное понятие. Каждая тема четко гармонирует с темами уроков. Учитель стремиться, чтобы эта программа помогла учащимся познать мир и самих себя.

Программа нацелена на воспитание нравственности, любви к родной земле, чувстве патриотизма, гордости за свою нацию.

Программа имеет исследовательскую значимость.

Программой могут пользоваться учителя района.

Хабибуллина З.Н.- доцент кафедры методики преподавания татарского языка и литературы Института развития образования Республики Татарстан.